КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 30 август г.Казань № 735

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы мәсьәләләре» 2007 ел, 22 август, 407 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы мәсьәләләре» 2007 ел, 22 август, 407 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2008 ел, 22 декабрь, 912 нче; 2010 ел, 19 июль, 577 нче; 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2012 ел, 7 февраль, 88 нче; 2012 ел, 12 октябрь, 847 нче; 2013 ел, 21 март, 196 нчы; 2013 ел, 11 июнь, 399 нчы; 2013 ел, 28 июнь, 446 нчы; 2013 ел, 29 август, 612 нче; 2014 ел, 17 гыйнвар, 21 нче; 2014 ел, 1 март, 133 нче; 2014 ел, 18 апрель, 255 нче; 2014 ел, 8 октябрь, 742 нче; 2015 ел, 22 гыйнвар, 28 нче; 2015 ел, 9 февраль, 72 нче; 2015 ел, 6 июль, 490 нчы; 2016 ел, 30 апрель, 269 нчы; 2016 ел, 9 июнь, 382 нче; 2016 ел, 12 октябрь, 737 нче; 2016 ел, 23 декабрь, 977 нче; 2017 ел, 6 март, 130 нчы; 2017 ел, 26 июнь, 439 нчы һәм 2017 ел, 7 декабрь, 950 нче; 2018 ел, 14 март, 151 нче; 2018 ел, 11 июнь, 461 нче; 2018 ел, 15 декабрь, 1139 нчы; 2019 ел, 15 июнь, 493 нче; 2019 ел, 2 июль, 525 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.3 пунктта:

3.3.6 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.3.6. Законнарда билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы милкендәге җир кишәрлекләрен сатучы функцияләрен башкара яки махсус оешмалар белән Татарстан Республикасы милкендәге җир кишәрлекләрен сату буенча аукционнар оештыручының вәкаләтләрен тапшыру турында килешүләр төзи.»;

түбәндәге эчтәлекле 3.3.6$^{1}$ пунктча өстәргә:

«3.3.6$^{1}$. Законнарда билгеләнгән тәртиптә хосусыйлаштырыла торган дәүләт мөлкәтен сатучы, шулай ук «Дәүләт һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль законның 6 статьясындагы 1 пунктының 81 пунктчасында күрсәтелгән юридик затларга Татарстан Республикасы исеменнән билгеләнгән тәртиптә хосусыйлаштырыла торган дәүләт мөлкәтен сатуны оештырырга һәм (яки) мондый мөлкәтне сатучы функцияләрен гамәлгә ашырырга йөкли.»;

түбәндәге эчтәлекле 3.3.102$^{1}$ пунктча өстәргә:

«3.3.102$^{1}$. Гавами сервитут билгеләү турындагы үтенечнамәләрне карый, җир кишәрлекләренең хокукына ия булучыларга гавами сервитут билгеләү мөмкинлеге турында хәбәр итүне тәэмин итә, законнарда билгеләнгән очракларда аларны карап тикшерүсез кире кайтару турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты хатлары проектларын әзерли, гавами сервитут билгеләү яки аны билгеләүдән баш тарту турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары проектларын әзерли.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин